Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Күл Черкене авыл җирлегенең Күл Черкене авылында гражданнар җыены карары

17.11.2022ел № 1

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Күл Черкене авыл җирлегенең Күл Черкене авылында гражданнар җыены

КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:

1. 2023 елда Күл Черкене авыл җирлегенең Күл Черкене авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәм сайлау хокукына ия балигъ булган гражданнарның һәркайсыннан 350 сум күләмендә үзара салым җыюны кертергә.

2. Җыелган акчаны түбәндәге җирле мәсьәләләрне хәл итүгә

- Күл Черкене авылында зиратны төзекләндерүгә (коймаларны яңарту, чүп үләннәр белән көрәш), кышкы чорда юлларны карап тоту, җәйге вакытта территорияне чабу (ягулык-майлау материаллары, запас частьләр сатып алу, килешү буенча эш һәм хезмәтләр өчен түләү), урам утлары сатып алуга һәм урнаштыруга юнәлдерергә.

3. Җыен нәтиҗәләрен Күл Черкене авыл җирлегенең Күл Черкене авылында махсус җиһазландырылган мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Халык җыенында рәислек итүче,
Күл Черкене авыл җирлеге башлыгы __________ М.К. Истиев

Халык җыены секретаре __________ И.Ю. Камалтдинова